Республика Татарстан
**ГЛАВА МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ «ПОСЕЛОК ГОРОДСКОГО ТИПА ДЖАЛИЛЬ» САРМАНОВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**
ул.Ахмадиева, д.26, п.Джалиль, 423368
Телефон: (85559) 31-0-97, 60-2-20, факс: 31-0-97
E-mail: POSSOVETD@mail.ru

Татарстан Республикасы
**САРМАН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ «ҖӘЛИЛ ШӘҺӘР ТИБЫНДАГЫ ПОСЕЛОК» МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ БАШЛЫГЫ**
Ахмадиев урамы, 26 йорт, Җәлил поселогы, 423368
Телефон: (85559) 31-0-97, 60-2-20, факс: 31-0-97
E-mail: POSSOVETD@mail.ru

ОГРН 1021601312501 ИНН/КПП 1636001410/163601001

ПОСТАНОВЛЕНИЕ — КАРАР

07.11.2022 ел — №6

## Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының Габдрахман авылында гражданнар җыенын 2023 елда үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча билгеләп кую турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы «Җәлил шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлеге Уставының 22 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы «Җәлил шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлеге башлыгы

**КАРАР БИРӘ:**

1. Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы, Габдрахман авылы, Габдрахман урамы, 15 нче йорт адресы буенча урнашкан торак йорт янында 2022 елның 17 ноябрендә 10.00 сәгатьтә 2022 нче елда Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Габдрахман авылында гражданнарның үзара салымын кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләргә.

2. Халык җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

«2023 елда 1500 сум күләмендә үзара салым кертү белән һәм Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының Габдрахман авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булмаган, I һәм II төркем инвалидларыннан, өлкән яшьтәге гражданнардан (80 яшьтән өлкәнрәк),

җирлек территориясендә ел дәвамында яшәүче гражданнардан, авыр тормыш хәлендә калган гаилә әгъзаларыннан тыш, РФ Президентының «Россия Федерациясендә өлешчә мобилизацияне игълан итү турында» 21.09.2022 № 647 Указы буенча мобилизацияләнгән гражданнардан һәм аларның гаилә әгъзаларыннан тыш, алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә җибәрү белән килешәсезме?:

1) чишмә территориясен төзекләндерү (төзелеш материаллары сатып алу, шартнамә буенча эшләр өчен түләү), су җыю урынын төзекләндерү (төзелеш материаллары сатып алу, шартнамә буенча эшләр өчен түләү), чишмәгә юлны ремонтлау (төзелеш материаллары сатып алу, шартнамә буенча эшләр өчен түләү), (эскәмия сатып алу) Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Габдрахман авылында

«РИЗА» «КАРШЫ?»

3. Әлеге карарны «Җәлил шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлегенең мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән Сарман муниципаль районының рәсми сайтында (http://sarmanovo.tatarstan.ru/), хокукый мәгълүматның рәсми сайтында (http://pravo.tatarstan.ru) кабул ителгән көннән биш көн эчендә бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Сарман муниципаль районы»
«Җәлил шәһәр тибындагы поселогы»
муниципаль берәмлеге башлыгы Р. Ә. Каримов